| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| --- | --- |
| ЮЛБАТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>САБИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЮЛБАТ АВЫЛ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| 422077, Республика Татарстан,<br>с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57<br>тел. (84362) 43-7-22 | 422077, Татарстан Республикасы,<br>Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт<br>тел. (84362) 43-7-22 |

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
01.07.2021 №28

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Юлбат авыл Башкарма комитеты
тарафыннан расланган 15.06.2021 елгы № 20
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Юлбат авыл җирлеге муниципаль торак
фондының социаль наем шартнамәләре һәм
муниципаль торак фондыннан торак урыннарны
яллаучылар өчен торак урыннардан (наемга түләү)
файдаланган өчен түләүне исәпләү тәртибе турындагы
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Төзелеш Министрлыгының 19.06.2017 елгы 892/пр номерлы боерыгы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номеры белән расланган «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү турында» боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннары наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннары наемга алучылар өчен торак урыннардан файдалану (наемга түләү өчен) күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында, Юлбат авыл Башкарма комитетының 15.06.2021 елгы 20 номеры белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге муниципаль торак

фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннары наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннарыннан (наемга өчен) файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы Нигезләмә" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Яллаучылар өчен түләү коэффициенты торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) билгеләнгән вакытка – 0,3 күләмендә билгеләнә.

Шул ук вакытта гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен түләүнең ташламалы критерийлары билгеләнә:

- 3 һәм аннан да күбрәк баладан торган күп балалы гаиләләр өчен-0,15;
- пенсионерлар өчен (55 яшькә җиткән хатын-кызлар һәм 60 яшькә җиткән ир-атлар) -0,15;
- инвалидлар өчен – 0,15.».

2.Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Юлбат авыл
җирлеге башлыгы Т.Р.Шәмсиев